5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Мифтахетдинова Н.Р. Балалар бакчасында оешкан мәгариф эшчәнлегендә мәгариф өлкәләрен интеграци-яләү // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2024. № 1 (20). URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2024/04/2024_1_miftakhutdinova.pdf

УДК 378.2

**Мифтахетдинова Надия Равил кызы**
Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесе, Россия, Казан шәһәре

# Балалар бакчасында оешкан мәгариф эшчәнлегендә мәгариф өлкәләрен интеграцияләү

***Аннотация.*** Мәкаләдә балалар бакчаларының мәктәпкәчә белем бирү оешмасында интеграцияләнгән процессны оештыруның үзенчәлеге карала. Оешкан белем бирү эшчәнлеген интеграцияләү технологиясе төрле булырга мөмкин, әмма һәр очракта да педагогның иҗади активлыгын күрсәтү кирәк. Бу аны үткәргәндә балалар сәләтләрен үстерү өчен мөһим шартларның берсе.
***Төп сүзләр:*** интеграцияләү, мәгариф өлкәләре, белем бирү процессының оештыру моделе

**Nadiya R. Miftakhutdinova**
Institute of Education Development of the Republic of Tatarstan, Kazan, Russia

# Integration of Educational Areas in Educational Activities Organized in Kindergarten

***Abstract.*** The article discusses the specifics of the organization of the integrated process of kindergartens in a preschool educational organization. The technology of integration of organized educational activities may be different, but in each case it is necessary to show creative activity of the teacher. This is one of the important conditions for the development of children's abilities during its implementation.
***Keywords:*** integration, spheres of education, organizational model of the educational process

## Кереш

Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты кертелү белән бәйле рәвештә педагогларның балалар белән эшләүнең эчтәлеген һәм формаларын яңа баштан аңлаулары бик мөһим. Мәктәпкәчә белем бирүнең эчтәлеге түбәндәге төп бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1. Баланың сәламәтлеген саклау.
2. Шәхеснең төп сыйфатларын үстерү.
3. Мәктәпкәчә яшьтәге баланың төп эшчәнлеге булып танылган уенны нигез итеп алып, белем бирү процессын төзү.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең программасы мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (ФДББС) тарафыннан билгеләнгән берничә принципка туры килергә тиеш. Шуларның иң мөһиме — үзенчәлекләренә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләрен интеграцияләү принцибы. Бу мәктәпкәчә яшьтәге балага тирә-юнь дөньясын бербөтен кабул итүне тәэмин итә.

## Материаллар һәм ысуллар

ФДББСта мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсешен тәэмин итә торган биш юнәле-

© Мифтахетдинова Н.Р., 2024

шендә карала һәм белем бирү юнәлешләре белем бирүнең биш өлкәсендә тәкъдим ителгән: социаль-коммуникатив үсеш, танып белү үсеше, сөйләм үсеше, сәнгать-эстетик үсеш һәм физик үсеш. Күп кенә шәхси сыйфатлар (мөстәкыйльлек, инициатива һ.б.), шулай ук тәрбияләнүчеләрнең белемнәре, күнекмәләре белем бирү өлкәләрен интеграцияләү һәм комплекслы-тематик принципны мәҗбүри исәпкә алганда гына формалаша, үсештә була  ала. Мәсәлән, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның эмоциональ яки иҗади үсешен ниндидер бер белем бирү өлкәсе кысаларына гына  кертеп карап  булмый. Эмоциональлек һәм иҗат балалар эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә дә үстерелә. Мәгариф өлкәләренең төп эчтәлеге түбәндәге компонентлардан тора: социаль-коммуникатив үсеш (әхлакый тәрбия, патриотик тәрбия, хокукый тәрбия, гендер тәрбиясе, коммуникатив үсеш, хезмәт тәрбиясе, тормыш иминлеге нигезләрен формалаштыру); танып белү үсеше (тирә-юньдәге социаль дөнья белән танышу, тирә-яктагы табигать дөньясы белән танышу, тирә-юньдәге предмет дөньясы белән танышу, элементар математик күзаллауларны формалаштыру, экспериментлар һәм тикшеренү эшчәнлеге, сенсор үсеше); сөйләм үсеше (сөйләмнең тавыш культурасын формалаштыру, сүзлек формалаштыру, сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үсеше, сөйләм иҗатын үстерү, нәфис әдәбият белән танышу); сәнгать-эстетик үсеш (сәнгать һәм әдәбият әсәрләрен кабул итүне үстерү, музыкаль үсеш, рәсем, ябыштыру, конструкцияләү, аппликация); физик үсеш (сәламәтлекне саклау һәм ныгыту,физик сыйфатларны үстерү, сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллаулар формалаштыру).

Балалар бакчалары педагогларына белем бирү процессының түбәндәге компонентларына күбрәк басым ясарга кинәш ителә (нинди максаттан чыгып, нәрсәгә ирешү өчен?):

- өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегенә (оештырылган белем бирү эшчәнлеге һәм режим моментлары вакытында);
- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлекләре вакытында.

Балалар белән өлкәннәрнең партнерлык эшчәнлеген оештыруның төп тезислары ачык эшләнгән:

- тәрбиясенең балалар белән бертигез эшчәнлеккә кертелүе;
- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның эшчәнлеккә үз теләкләре белән кушылуы (психик һәм дисциплинар мәҗбүрилексез);
- эшчәнлек вакытында балаларның ирекле аралашуы һәм хәрәкәт итүләре, күченүе (эш киңлеген оештыруга туры килгәндә);
- эшчәнлекнең вакыт кысаларына кертелмәве, ачык вакытлы ахыры (һәркем үз темпында эшли).

ФДББСта белем бирү эшчәнлеге балалар эшчәнлегенең төрле формаларын оештыру процессында, шулай ук режим моментларында, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге вакытында һәм балалар бакчасында тәрбияләнүчеләренең гаиләләре белән үзара хезмәттәшлек барышында башкарыла дип билгеләнгән.

“Интеграция” нәрсә ул? Интеграция — мәктәпкәчә белем бирүдә аерым белем бирү өлкәләренең үзара бәйләнеше, бер-берсе белән керешүе һәм үзара тәэсир итешү халәте (яки мондый халәткә алып баручы процесс), ул белем бирү процессының бөтенлеген тәэмин итә [1].

Интеграцияләнгән шөгыль — ул тәрбияләнүчеләргә белем бирүнең төрле өлкәләренә караган белемнәрне берләштереп бирү, танып-белүгә чыгарылган мәсьәләне практик чагылышта күрсәтү. махсус оештырылган шөгыль, аның максаты төрле белем бирү өлкәләреннән белемнәрне берләштергәндә генә ирешелергә мөмкин, ул тәрбияләнүчеләргә тикшеренүче мәсьәләне практик юнәлештә тербөтен кабул итүгә ирешергә мөмкинлек бирә. Белем бирү эшчәнлегенә интеграцияләнгән караш мәктәпкәчә дидактиканың төп таләпләренең берсе булып тора: белем күләме буенча кечкенә, әмма мәгълүматлы сыйдырышлы булырга тиеш [2]. Инте-

грацияләнгән алымның актуальлеге түбәндәгеләр берничә сәбәп белән аңлатыла:

1. Интеграцияле белем бирү балаларда дөньяның бербөтен картинасын формалаштыруга ярдәм итә, иҗади сәләтләрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

2. Интеграцияләнгән белем бирү эшчәнлеге барышында тәрбияләнүчеләрнең үз мөмкинлекләре потенциалы үсеш ала: аларның әйләнә-тирәдәге чынбарлыкны актив тану, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен аңлау, табу, логик фикерләү һәм гомумән фикерләү, коммуникатив сәләтләреүстерелә.

3. Шөгель барышында төрле эшчәнлек төрләрен куллану тәрбияләнүчеләрнең игътибарын югары дәрәҗәдә саклый, бу исә дәресләрнең нәтиҗәлелеге турында сөйләргә мөмкинлек бирә.

4. Интеграцияләнгән алымның асылы — төрле өлкәләргә караган белемнәрне тигезлек нигезендә берләштерү, белемнәрне бер-берсе белән тулыландыру.

5. Интеграция педагогныңүзенең дә мөмкинлекләрен гамәлдә кулланырга, иҗади мөмкинлекләрен, сәләтен һәм, гомумән, үзен күрсәтергә мөмкинле бирә, үз-үзен тормышка ашырырга, үз-үзен белдерү, иҗатын, аның сәләтләрен ачу мөмкинлеге бирә.

**Нәтиҗә**

Оешкан белем бирү эшчәнлеге интеграциясендә кулланыла торган ысуллар һәм алымнар:

- сюрприз, уен мизгелләре;
- карау, күзәтү, чагыштыру, тикшерү;
- чагыштыруга нигезләнгән анализ, чагыштыру, эзләү;
- балага җавап табарга ярдәм итүче педагог белән бергәләп ачышлар ясарга этәргеч булып торырлык проблемалы сораулар; уткәрүне стимуллаштыручы проблемалы сораулар;
- сүзлекне активлаштыру, туган телнең төрле яклары турында күзаллауны киңәйтү, үз көчләренә ышаныч хисе тәрбияләү өчен төрле дидактик уеннар.

**Фикер алышу**

Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге, беренче чиратта, тәрбияче шәхесенә бәйле сыйфатлы нәтиҗәсе программадан гына түгел, ә иң элек баланың белемнең теге яки бу өлкәсен үзләштерү өчен эмоциональ яктан тулган мохит булдыручы өлкән кешенең шәхесенә бәйле (режим моментлары, мөстәкыйль балалар эшчәнлеге). Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә интеграция процессын аерым бер шөгыль, нинди дә булса тематик чара кысаларында уткәрергә мөмкин, интеграцияләнгән процессны оештыруның үзенчәлеге шунда ки, хәтта шөгель яки чара өчен билгеле бер теманы сайлау да интеграцияне күздә тота. Мисал өчен, 8 Мартка багышлап оештырылган чарада социаль — коммуникатив, танып белү, сәнгать-эстетик үсеш өлкәләре, иҗаи, уен, танып белү, тикшерену эшчәнлекләренә нигезләнеп оештырылырга мөмкин. Ә оештырубәйрәм яки ял формасында булырга мөмкин.

Мәктәпкәчә оешмаларда проект методын куллану мәктәпкәчә яшьтәге балаларны интеграцияле укыту методларының берсе. Проект — ул өлкәннәр тарафыннан махсус оештырылган һәм балалар тарафыннан башкарыла торган эш комплексы, ул иҗади эшләр белән тәмамлана. Проектлар ысулы — балалар даими катлаулана торган практик биремнәрне планлаштыру һәм үтәү процессында белемнәр ала торган укыту системасы. Проектлар методы һәрвакыт тәрбияләнүчеләрнең ниндидер проблеманы чишүләрен күздә тота.

Проектлар ысулы баланың эш итү комплексын һәм бу гамәлләрне педагог оештыру ысулларын (техникасын) тасвирлый, ягъни педагогик технология булып тора. Бу ысулны белем бирү процессында куллану командада эшләргә өйрәнергә ярдәм итә, куелган максатка ирешү өчен үз эш итү алгоритмы эшләнә. Педагоглар эшчәнлек ысулларын һәм төрләрен сайлауда иректе. Проектның билгеле бер темасын сайлау аңа белем бирү өлкәләрен сайлауны да билгели, алар балага аның эчтәлеген һәрьяклап ачачак [2].

Мәсәлән, «Ватанны саклаучылар көне» темасы барлык белем бирү өлкәләрен сайлауны билгели. Атна дәвамында балаларга Россия армиясе турында әсәрләр укыйлар,

армия турында картиналарның репродукцияләрен карыйлар, «безнең әтиләр — солдатлар» күргәзмәсе, армия турында коллаж, уенчык хәрби техника, хәрби форма күргәзмәсе әзерләнә. Шөгыль барышында армия турында сөйләшәләр, гаскәрләр төрләре, хәрби форма, техника белән танышалар, төрле сөйләм уеннары уйныйлар, картиналар сериясе буенча хикәя төзиләр, әтиләренә бүләк ясыйлар, армиягә багышланган музыкаль әсәрләр тыңлыйлар, соңыннан бергәләп «Көчлеләр, кыюлар, җитезләр» спорт бәйрәме оештыралар.

Педагогның балалар белән интеграция нигезендә уртак эшчәнлегененңүрнәк структурасы:

1. Кереш өлеш. Балаларның активлыгын арттыру өчен проблемалы хәл тудырыла (мәсәлән, "Балалар, җирдә су булмаса, нәрсә булачак?" — дигән сорау бирелә).

2. Төп өлеше. Балаларга проблемалы мәсьәләне хәл итү өчен кирәкле яңа белемнәр бирелә (мәсәлән, табигатьтә һәм кеше тормышында суның әһәмияте һ.б.) программаның төрле бүлекләренең эчтәлеге нигезендә, сүзлекне баету һәм активлаштыру, бәйләнешле сөйләмне өйрәтү буенча эш параллель бара.

3. Соңгы өлеш Алынган мәгълүматны ныгыту яки элек үзләштерелгән мәгълүматны актуальләштерү өчен төрле гамәли эшләр (дидактик уеннар, рәсем ясау һ.б.) тәкъдим ителә. Барлык белем бирү эшчәнлеге интеграция һәм тематик планлаштыру нигезендә төзелә.

**Нәтиҗә өлеше.**

Шулай итеп, мәктәпкәчә белем бирүдә ФДББС мәктәпкәчә яшьтәге балаларны заманча шартларда үстерү, баланың белем алу хокукын гамәлгә ашыру өчен оптималь шартлар булдыруга юнәлдерелгән. Оешкан белем бирү эшчәнлеген интеграцияләү технологиясе төрле булырга мөмкин, әмма һәр очракта да педагогның балараның сәләтен үстерүгә юнәлдерелгән иҗади активлыгы үзәктә булырга тиеш.

Кулланылган әдәбият
1. Белая К.Ю. Интеграция — ключевой инструмент для создания новой модели детского сада // Управление ДОУ. 2003. № 4. С. 105–109.
2. Современные образовательные практики: интеграция образовательных областей в организованной образовательной деятельности ДОО: метод. пособие. Казань: ГАОУ ДПО ИРО РТ, 2023. С. 2.

References
1. Belaya K.Y. Integration — a key tool for the creation of a new model of kindergarten. *Upravlenie doshkol'nym obrazovatel'nym uchrezhdeniem=Management of pre-school educational institution Journal*. 2003;4:105–109. (In Russ.)
2. Modern educational practices: integration of educational areas in the organized educational activities of the pre-school education organizations. Kazan. Institute of Education Development of the Republic of Tatarstan, 2023, p.2.